КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 апрель

г.Казань

№ 388

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибен һәм методикасын раслау турында» 2020 ел, 15 июнь, 495 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибен һәм методикасын раслау турында» 2020 ел, 15 июнь, 495 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2 өлешнең 1 пункты белән» сүзләрен «1 өлешенең 19 пункты, 2 өлешенең 1 пункты белән» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Оешмалар мөлкәтенә салым һәм оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын куллану шартларын салым түләүчеләрнең аерым категорияләрен үтәүне бәяләү тәртибе һәм методикасының беренче абзацында «2 өлешнең 1 пунктындагы дүртенче абзацы белән» сүзләрен «1 өлешенең 19 пунктындагы бишенче абзацы , 2 өлешенең 1 пунктындагы дүртенче абзацы белән» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин